Беренче сентябрьдән клиентка тvләv картасын рәсмиләштергән банклар, банкоматлар аша акча биргәндә, кешенен мошенниклар йогынтысында булмавын, шулай ук анын очен операция ясамавын тикшерергә тиеш. Әлеге хәбәр “Трубканы куй”дан алынды.   Россия банкы кредит оешмалары таяначак тугыз билгене билгеләгән. Алар арасында: акча алуда кешегә хас булмаган тәртип: тәvлекнен гадәти булмаган вакыты; банкоматнын типик булмаган суммасы яки урнашу урыны; клиентка хас булмаган ысул белән акча бирvне сорау - мәсәлән, картадан тvгел, ә QR-код буенча.
Операциягә кадәр ким дигәндә 6 сәгать алдан телефон сойләшv-ләренен активлыгы, яна номерлардан СМС саны арту, шул исәптән мессенджерларда.
Кредит яки займ рәсмиләштергән-нән сон 24 сәгать эчендә акча алу яки акчалата бирvгә лимитны арттыру, шул исәптән кредит картасы буенча. Кеше тарафыннан vз счетына башка банктагы СБП буенча 200 мен сумнан артык акча кvчерv яки шундый ук суммага кертемне вакытыннан алда ябу.
Интернет-банкта авторизация очен телефон номерын алыштыру, (шул исәптән элемтә операторларыннан) клиент акча тошерә торган телефоннын характеристикалары vзгәрvе яки анын жайланмасында зарарлы программалар булуы турында мәгълvмат алу.
Әгәр операция критерийларнын берсенә генә булса да туры килә икән, банк бу хакта кичекмәстән клиентка хәбәр итәчәк һәм 48 сәгатькә банкоматта акча бирv очен вакытлы лимит кертәчәк - тәvлегенә 50 мен сумга кадәр. Бу чорда зуррак сумманы банк бvлекчәсендә алырга момкин. Мәгълvмат бирv ысулы клиентнын банк белән килешvе белән каралган. Кагыйдә буларак, бу СМС яки пуш-белдерv.
Тагы бер тапкыр Россия студентларын һәм мәктәп укучыларын телефон һәм интернет аша эш итvче мошенниклар алдый башлаган алдакчылар турында. «Интеллектуальная аналитика» компаниясе белгече Тимофей Воронин шул хакта яза. Воронин болай анлата: мошенник студентка мәгариф департаменты, вуз яки министрлык исеменнән шалтырата яки мессенджер аша язган хәбәрдә студентка яки укучыга мәжбvри тестны узмавын, шуна кvрә хәзер ана нәрсәдер янавын әйтә. Ә инде «проблеманы хәл итv очен» жибәрелгән сылтамага кичекмәстән кереп, сораштыру узарга тәкъдим ителә. Чынында бу – ялган сайт-тозак. Максаты – яшерен мәгълvматларны: паспорт мәгълvматларын, Дәvләт хезмәтләре порталындагы логин һәм парольләрне урлау.
- Шунысын истә тотарга кирәк: чын мәгариф учреждениеләре яки дәvләт органнары хезмәткәрләре укучыларга мессенджерлар аша тест узу очен сылтамалар жибәрми, – дип басым ясап әйткән Воронин. Белгеч мондый сойләшvне кичекмәстән туктатырга, сылтамалар аша узмаска һәм бернинди дә мәгълvматлар бирмәскә чакырган, дип әйткән Воронин.